# Татар теле атналыгы планы

| Дата | Чара | Җаваплы кеше |
|---|---|---|
| 21.02 | **«Туган телне кадерләгән халык кадерле булыр»**<br>Әдәби монтаж<br><br>#ӘдәбиМарафон#ТуганТел | Зәйнуллина Г. Н. |
| 22.02 | “Солдатта булган диләр”<br>Шигырь сөйләүчеләр бәйгесе | Зәйнуллина Г. Н. |
| 23.02 | quizizz - викторина "Мин - тел белгече" (онлайн) | Зәйнуллина Г. Н. |
| 24.02 | 8 нче сыйныфта татар әдәбиятыннан ачык дәрес. “Хәзерге заман татар шигърияте. | Зәйнуллина Г. Н. |
| 25.02 | "Клавиатура" уены. | Зәйнуллина Г. Н. |
| 26.02 | Йомгаклау. | Зәйнуллина Г. Н. |

**Әлки муниципаль районы**
**“Әхмәт төп гомуми белем мәктәбе” МББУ**

# «Туган телне кадерләгән халык кадерле булыр»

Әдәби монтаж




**Авторы: Зәйнуллина Гөлшат Нурсәлим кызы,**
югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Татар Әхмәте, 2022**

**Максат**: укучыларда ана телләренә һәм башка телләргә карата кызыксыну һәм хөрмәт тәрбияләү; Туган тел көне турында мәгълүматларын арттыру, иҗади сәләтләрен үстерү, милли үзаң, милли горурлык хисләре булдыру;

**Бурычлар**: халкыбызның бай, рухи мирасын барлауга ихтыяҗ тудыру; төрле телләрдәге җырлар, шигырьләр аша укучыларда ана телләрен өйрәнү, аны ярату, хөрмәт итү теләге тудыру;

**Җиһазлау**: мультимедиа слайдлары, музыкаль бизәлеш, “Иң татлы тел-туган тел”, “Теле барның- иле бар”, “Туган телем – киңдер сиңа күңел түрем” плакатлары.

Зал бәйрәмчә бизәлгән. Балалар һәм килгән кунаклар залга кергәндә, “ Туган тел” көе яңгырап тора. "Туган тел" мультфильмы күрсәтелә.

**1 алып баручы**: Хәерле көн димен барчагызга,
Кояшлы көн телим гөлләргә,
Сөйкемлелек телим яшь кызларга
Ә батырлык сезгә - егетләргә!

**2 алып баручы:** Добрый день, дорогие друзья! Сегодня мы собрались не случайно. По решению ЮНЕСКО именно 21 февраля - Международный день родного языка . Сегодня большой праздник. И в этом зале собрались, чтобы воспеть свой родной язык – великий, необъятный, «живой, как жизнь».

(Слово для поздравления директору школы Гайнутдиновой В.С.)

**1 алып баручы:** 21 февраль – Халыкара туган тел көне. Дөньяда 7000 гә якын тел бар. Шуларның 83е киң таралган. Ә 383 тел бөтенләй юкка чыгарга мөмкин. Бала тугач та, беренче ана телен ишетә. Шуңа күрә халкыбыз туган тел турында “Иң татлы тел – туган тел, анам сөйләп торган тел”, - дип әйткән дә. Әйдәгез шул турыда тыңлап китик. Сүзне 1 нче сыйныф укучыларына бирәбез.

Туган тел-иң татлы тел,
Туган тел-иң тәмле тел.
Тәмле диеп, телең йотма-
Туган телне онытма!
Туган телемдә сөйләшеп
Яшим мин туган илдә.
“Туган ил”дигән сүзне дә
Әйтәм мин туган тел

Иң изге хисләремне мин
Туган телдә аңлатам.
Шуңа күрә туган телне
Хөрмәтлим мин, яратам.

Халкым теле-хаклык теле,
Аннан башка минем илем юк;
Илен сөймәс кенә телен сөймәс,
Иле юкның гына теле юк.
Күзләремне ачты минем,
Иркәләде үз телем.
Үз телем яктыртты юлны,
Үз телем бирде белем.

Игелекле булып үсим
Газиз туган телемә.
Туган тел бер генә була,
Әнкәй кебек-бер генә.
Әткәң-әнкәң телен белсәң,
Адашмассың кайда да.
Туган телемдә эндәшәм
Кояшка да, айга да.
Туган телемдә аңлашам
Үткән, бүгенем белән.
Әлифбамны, дога итеп
Укыймын күңелемнән.
Халкым бер тумыш көнендә дә
Тукаен онытмады.
Без-“Туган тел”дән туганнар
Без- Тукай оныклары.

**2 алып баручы**: Один из постулатов древности гласит: «Врата мудрости никогда не бывают закрытыми». Изучая родной язык, (а у нас в республике, это государственные языки –русский, татарский, а для других национальностей – это чувашский, марийский, мордовский и другие языки), вам, возможно, удастся чуть пошире распахнуть эту таинственную дверь мудрости.

**1 алып баручы** Татар теле – ЮНЕСКО тарафыннан бөтендөнья халыкара аралашу теле дип саналган 14 телнең берсе. Бу – туган телебез белән горурланырлык мөһим фактор.

Алып баручы: туган тел. Һәркем өчен дә газиз сүз бу. Чөнки иң кадерле, бернәрсә белән дә алыштырылмый торган “әни”, “әти”,”әби”, “бабай” сүзләрен башлап туган телдә әйтәбез. Туган үскән ил-җирнең якынлыгын, Ватанның газизлеген без туган тел ярдәмендә тойганбыз. Шагыйрьләребезнең матур-матур шигырьләрен ятлап, әле дә куанабыз, рухланабыз. *(Шиһапова Азалия башкаруында. Равиля Файзуллина “Туган тел турында бер шигырь”)*

Равил Фәйзуллин, **“Туган тел турында”**
И кардәшем! Бер хаҗәтсез кайчак
Телне шундый бозып сөйлисең!
Ил колагын хурлап, халкыңның
Рухын рәнҗетәмен димисең.
Мескенләнмә, бакый гомер килгән
Тел байлыгын итмә кадерсез.
Бер уйласаң, илаһи бит, изге –
Кеше әйткән аваз, һәрбер сүз!
Иренмә син, туган, туган телнең
Асыл байлыкларын ачарга.
Без ваемсыз булсак, чит-ят сүзләр
Хәзинәңне әзер басарга!
Күп телләрне белү – яхшы шөгыль,
Туган телең үги калмаса.
Җанын салып әйткән эткәң сүзен
Синең аша балаң аңласа.
Киләчәкнең башы – бүгенгедә.
Нинди шатлык картлык көнеңдә,

Оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә,
Матур итеп туган телендә.

**2 алып баручы:** Великий татарский поэт Габдулла Тукай понимал, как необходимо для татарского народа приобщение к русской мировой культуре, сближение его с другими народами и их языками.

Нам издавна другом был русский народ.
И разве конец этой дружбе придет?
Да, мы родились и растем в вышину.
Нанизаны словно на нитку одну.

**1 алып баручы** Родные языки множества наций, проживающих у нас в Татарстане «Нанизаны словно на нитку одну». Их цель одна – передать мудрость, накопленную веками – своим потомкам.

*Татар кызлары биюе*




**2 алып баручы:** Наш родной язык как хлебосольный хозяин радушно распахивает двери перед языками других национальностей, обогащаясь в свою очередь словами и выражениями. Ничто на свете не связано с человеком так прочно как язык. Нет на свете лучше средства общения. Чем лучше ты владеешь родным языком, а также другими языками, тем больше у тебя права называться человеком ( ученики 3 класса )

“Татарча да яхшы бел,
Урысча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле, затлы тел.

Татарчасы – туган тел,
Безгә газиз булган тел.
Атаң – анаң, әби – бабаң
Сине сөя торган тел.

Бу телдә рух байлыгың
Һәм йөрәк кайнарлыгың,
Җырлаган бу телдә безгә
Сөекле Тукай моңын.”

Тел дигән дәрья бар,
Дәрья төбендә мәрҗән бар.
Белгәннәр чумып алыр,
Белмәгән карап калыр.
Нәкый Исәнбәт
И нет у нас иного достоянья!
Умейте же беречь
Хоть в меру сил, в дни злобы и страданья,
Наш дар бесмертный – речь.
И.А.Бунин
Татар теле – туган тел,
Безнең газиз булган тел
Әти-әни, әби-бабай
Безне сөя торган тел.
Шәйхи Маннур

**1 алып баручы** Һәр халыкның туган теле – аның мәдәнияте, тарихи көзгесе. Шуңа да телебез сафлыгы, матурлыгы, аһәңлелеге өчен барыбызга да армый-талмый көрәшергә, эшләргә кирәк.

Г. Гыйльманов, **“Мин татар малае”**

Чатнатып сөйләшәм
Үз ана телемдә.
Оялмыйм, курыкмыйм,
Мин бит үз илемдә!
Башымда – чигүле,
Каюлы түбәтәй.
Догалар укырга
Өйрәтә дәү әтәй
Тәүфыйклы булырга
Кирәген беләм мин.
Чын татар малае
Йөрәгем белән мин.

**2 алып баручы** Говоря каждый на своем родном языке, гражданин мира привносит в него что –то свое, собственное, но всегда нужное и полезное.

**1-й ученик**. Прекрасные мастера слова М. В. Ломоносов, Н.В.Гоголь, Н.М.Карамзин, М. Горький высоко ценили русский язык. А.С.Пушкин писал: «Как материал словесности, язык славяно-русский имеет неоспоримое превосходство перед всеми европейскими…»



Слова, слова…
Слова, слова, слова.
Как много их на свете.
Но лучше всех звучат они
В родном краю. При этом
Словами можно выражать
Все мысли наши с вами.
Мы можем даже возражать
Красивыми словами/

Словами – любим и поем,
Словами – жизнь решаем.
Словами можем убивать,
Словами воскрешаем.
Богатство слов у нас такое,
Что можно быть богатым.
Богатым в деле и в письме,
В кино, в науке и в театре.
Родной язык, он так красив.
Журчит он, словно речка.
Красивых очень много слов.
Плохим словам – нет места

**1ал.баручы:** Великий татарский поэт Габдулла Тукай понимал, как необходимо для татарского народа приобщение к русской мировой культуре, сближение его с другими народами и их языками.

**2 алып баручы** Халкым бер тумыш көндә дә
Тукаен онытмады:
Без — «Туган тел»дән туганнар —
Без — Тукай оныклары!

- Әйдәгез әле бергәләшеп , Г. Тукайның " Туган тел" җырын башкарыйк.

*( Габдулла Тукайның “Туган тел”җыры җырлана)*

**1 алып баручы:**

Отмечая Международный день родного языка... мы отдаем дань уважения несметному числу существующих в мире языков, культурам, которые они отражают. В Международный день родного языка все языки признаются равными, поскольку каждый представляет живое наследие, которое нам следует оберегать.

**2 алып баручы** Туган тел төшенчәсенә зур мәгънә салынган. Ул Ватан, туган җир, ата-ана сүзләре белән бер үк дәрәҗәдә торучы бөек, изге һәм кадерле сүз. Ул телне шуңа күрә туган тел дип атыйлар да. Ул телгә баланы аның иң газиз, иң якын кешесе – әнисе өйрәтә, шул телдә аңа бишек җырларын җырлый, иркәли, юата.

***Бишек җыры***

**1 алып баручы:** «Русский народ создал русский язык, яркий, как радуга после весеннего ливня, меткий, как стрелы, певучий и богатый, задушевный как песня над колыбелью… Настанет время (и оно не за горами), когда русский язык начнут изучать по всем меридианам земного шара». В наши дни сбылось предвидение писателя: русский язык стал одним из широко известных мировых языков.

**3-й ученик**.
Если хочешь судьбу переспорить,
Если ищешь отрады цветник,
Если нуждаешься в твердой опоре —
Выучи русский язык!
Он твой наставник великий, могучий,
Он переводчик, он проводник.
Если штурмуешь познания кручи—
Выучи русский язык!

**1 алып баручы** Потрогать, увидеть язык нельзя. Но однако, он все-таки есть! Исчезнет он- и мы попросту перестанем понимать друг друга. Язык- это слово, а слова, положенные на музыку становятся песней

**2 алып баручы**
Родной язык. Он впитан с молоком.
Звучит как музыка, нам сердце услаждая
В международный день родного языка
На языке родном тебе мы пожелаем:
Люби язык, храни на день и на века!
Не забывай мелодию родного языка.

Җирдә миңа ни кирәк? (Ш.Галиев)
Җирдә миңа ни кирәк?
Әти дә әни кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Без яшәгән өй кирәк!
Әти дә әни кирәк!
Без яшәгән өй кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Әллүкиле көй кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Тукай туган тел кирәк!
Әллүкиле көй кирәк!
Тукай туган тел кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Туган-үскән ил кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Мәңге имин Җир кирәк!
Туган-үскән ил кирәк!
Мәңге имин Җир кирәк!

***
Туган илебез (Х.Вахит)
Без — бәхетле, шат балалар,
Без кайгыны белмибез,
Эх, ямьле соң, күңелле соң
Безнең Туган илебез!
Болыннарда, бакчаларда
Уйнап-җырлап йөрибез.
Эх, киң дә соң, иркен дә соң
Безнең туган җиребез.

Нурлар белән, гөлләр белән
Бизәлгән һәр көнебез.
Эх, зур да соң, матур да соң
Безнең Туган илебез.

***

“ Туган телем.” Э. Мөэминова.
Дөньяда иң – иң матур ил -
Ул минем туган илем.
Дөньяда иң – иң матур тел –
Ул минем туган телем.
Иң изге хисләремне мин
Туган телдә аңлатам.
Шуңа күрә туган телне
Хөрмәтлим мин, яратам.

Рафис Корбанов, **“Туган ил”**
“Әткәм”, “әнкәм” сүзе белән
Ачылган телем минем.
Син бирдең миңа ышаныч
Кичкәндә белем илен.
Ата-бабамнар үткәнен
Белдем мин синең аша.
Башка телләрең эченә
Кердем мин синең аша



**<u>Алып баручы.</u>** Кадерле балалар! Шуның белән кичәбез тәмам. Сезнең һәммәгезгә дә актив катнашканыгыз өчен рәхмәт. Исән булыгыз, туган телегезне, туган җирегезне хөрмәт итегез, онытмагыз, Татарстаныбызның лаеклы уллары һәм кызлары булып үсегез.

## #әдәбимарафонӘхмәт

Укучылар атна дәвамында әлеге хештег белән үзләренең социаль челтәрләрдәге битләренә туган тел турында шигырьләр урнаштырдылар. Әлеге заманча чара туган телгә, әдәбиятка игътибарлы булырга өнди, виртуаль дусларны да шуңа чакыра.






“Солдатта булган диләр”

Шигырь сөйләүчеләр бәйгесе

1-8 сыйныф укучылары солдат хезмәте, сугышчылар турында язылган татарча шигырьләр белән чыгыш ясадылар. Әлеге чара туган илгә карата мәхәббәт тәрбияләү, сәнгатьле сөйләү, чыгыш ясау осталыгын үстерү максатыннан үткәрелде.





# “Хәзерге татар шигърияте” темасына ачык дәрес

**Дәреснең максаты**: 1. Укучыларны хәзерге заман шигърияте, “Кыска шигырьләр” жанры белән таныштыру, Р.Фәйзуллин иҗатына күзәтү ясау.

2. Тәнкыйди фикерләүне үстерү өчен шартлар тудыру.

3. Шигърияткә карата мәхәббәт тәрбияләү, Р.Фәйзуллин иҗаты белән кызыксыну уяту.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Предмет УУГ**: алга таба үсү өчен, татар әдәбиятын укуның һәм өйрәнүнең әһәмиятен аңлау;

**Метапредмет УУГ:**

**Регулятив УУГ**: үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне бәяләү нигезләренә ия булу, карарлар кабул итә белү.

**Коммуникатив УУГ**: текстның асылын аңлый белү, сөйләм чараларыннан, үз хисләрен, уй-фикерләрен, ихтыяҗларын белдерү өчен. аңлы рәвештә файдалану;

**Танып белү УУГ**: өйрәнелә торган текстның төп идеясен билгеләү.

**Шәхси УУГ**: укучыларның үз-үзен тотышын һәм гамәлләрен, шулай ук башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышын һәм гамәлләрен әхлакый һәм хокукый нормалар позициясеннән чыгып бәяләргә әзер булу, гамәлләрнең нәтиҗәләрен аңлый белү.

Дәрестә укучыларның иҗади фикерләвен, иҗади сәләтләрен үстерү, аңлап укуга ирешү, туган телдә әдәбиятка кызыксыну уяту максатлары тормышка ашырылды. Бу дәрестә укучылар шигырьне анализлау алгоритмын этаплап кабатладылар, парларда кыска шигырьләрне анализладылар. Шигырьне анализлау өчен, 6 эшләпә алымы кулланылды. Дәрестә укучыларның уку грамоталылыгын үстерү буенча эш алып барылды.

Дәрес башында укытучы бәяләү критерийлары белән таныштырды, укучылар үз белемнәрен бәяләделәр. Рефлексия үткәрелде. Дәрес бик уңышлы узды, ФГОС таләпләренә туры килде.





24 февральдә “**Клавиатура**” уены үткәрелде. Чараның максаты: үзара аңлашу, үзара ярдәмләшү, дустанә мөнәсәбәтләр тәрбияләү өчен шартлар тудыру.

Укучылар 2 командага бүленделәр, аларга хәрефләр, тыныш билгеләре һәм, әгәр команда ялгышса һәм хәрефне сызарга кирәк булса, "Backspace" төймәсе таратылды. Уен шартлары буенча катнашучылар дәшми генә уйнадылар.

1 тур: алып баручы һәр командага сүзне күрсәтә, алар сүзне истә калдыра һәм хәрефләп сүзне тактада язып баручы команданың бер катнашучысына күрсәтә. Сүзне тизрәк язган команда җиңә.

2 тур. Команда бөтен бер гыйбарәне истә калдырырга һәм такта янындагы бер уенчыга хәрефләп  күрсәтеп яздырырга тиеш.

3 тур - һәр команда икегә бүленә, шулай ук хәрефләр белән дә эшлибез. Һәр төркем үзләренә эләккән хәрефләрнең 7 хәрефеннән сүз төзергә тиеш.

4 тур - катнашучылар, килешмичә, чара темасы буенча сүз төзергә тиеш.




